Профсоюзное объединение Евлаштауской СОШ долгие годы возглавляли Ахатова Р.А., Гильметдинова М.Ю.,(1960-1980), Шаймуллин М.Ш. (1980-1990) Мухамет Шаймуллович пользовался среди односельчан заслуженным авторитетом, вел активную разъяснительную и просветительскую деятельность.
С 1992 года профсоюз возглавила Мусина С.З. В содружестве с дирекцией школы ей удалось добиться дружелюбной рабочей атмосферы в коллективе, решения насущных проблем оптимальными методами.
На сегодняшний день профсоюз школы - это сплоченный коллектив единомышленников, ценящих и уважающих друг друга. В этом немаловажна заслуга и нынешного председателя профкома - Шакировой М.М.

Тарих эзләреннән...

Россиядә мәгариф өлкәсендә эшләүчеләрне берләштерүче оешма 1905 елда барлыкка килгән. 1917 елда әлеге оешма Бөтенроссия укытучылар союзы исемен ала. Аларның политик эшчәнлеге советларга каршы була. Шуңа күрә 1918 елда РСФСР җитәкчелеге оешманы бетерү турында нигезләмә чыгара. Укытучы-интернационалистлар II съездларын җыя һәм Бөтенроссия мәгариф һәм социалистик мәдәният хезмәткәрләрен берләштергән оешма төзергә карар кыла. 1919 нчы елдан мәгариф хезмәткәрләре совет профессиональ хезмәткәрләр хәрәкәтенә кушыла. СССР чорында профсоюз оешмалары берләштерелә, зурайтыла. Аның составына мәдәният, мәгариф һәм фән, сәнгать оешмалары кертелә дә, чыгарыла да.

Явлаштау мәктәбендә профсоюз оешмасын 1960 нче еллардан озак еллар



Әхәтова Рәшидә Әхәтовна, аннан соң, Гыйльметдинова Мәхтүмә Юзмиевна,1980-90 нчы елларда Шәймуллин Мөхәммәт Шәймуллович җитәкли. Мөхәммәт Шәймулловичны һәр нәрсә белән кызыксынучы, күп укыганы һәм белгәне өчен авылда “аяклы энцеклопедия” дип йөртәләр. Яше, карты аңа киңәшкә килә, ихтирам итә. Коммунист укытучы халык арасында, җәмәгать эшләрдә актив катнаша, халыкара-хәлләр, хөкүмәтебезнең карарларын халыкка җиткерү буенча даими лекциләр укый. Ата-аналар, балалар алдында тәрбия темасына докладлар белән чыга.



Мөхәммәт Шәймуллович лаеклы ялга киткәннән соң, 1992 нче елдан Мусина Сәридә Зәкәриевнаны профком рәисе итеп сайлыйлар. Ул армый-талмый эшләүче педагог. Һәрбер профсоюз членына ярдәм итә, теге яки бу мәсьәләләрне хәл итүнең оптималь юлларын билгели, эшләгәнне күрә, бәяли белә. Шушы алымнар белән директор белән берлектә коллективта хезмәттәшлеккә, ярдәмләшүгә корылган эшлекле халәт тудыруга ярдәм итә.



Мәктәптә укытучылар коллективында хезмәттәшлек, таләпчәнлек, бер-береңне аңлап эшләү мөхите барлыкка килүдә Шакирова Марсилә Мәҗитовнаның да өлеше зур.

Мәктәп директоры Гыйбадуллин Зөлфәт Фоатович, завучлар Шакирова Земфира Ренатовна һәм Шиһабиева Фәйрүзә Нурисламовналар , профсоюз оешмасы рәисе Марсилә Мәҗитовна белән берлектә нинди генә киртәләр булуга карамастан, коллективны укыту һәм тәрбия процессының бердәмлегенә ирешеп, алга куелган бурычларны уңай хәл итеп киләләр. Әлеге состав 2000 нче елда мәктәп яңа ике катлы бинага күчеп, урта мәктәп статусы алганнан бирле социаль хезмәттәшлектә эшли. Ул вакытта башлангыч профсоюз оешмасына Явлаштау урта һәм Мишәбаш башлангыч мәктәпләре генә керсә, 2006 нчы елдан башлангыч профсоюз оешмасына Явлаштау һәм Мишәбаш авылларының балалар бакчалары да кушыла. 2011 нче елдан мәктәпләрдә эшләүче техник хезмәткәрләр “ХЭК” оешмасына күчә һәм алар мәктәп профсоюзы членнары булудан туктыйлар. Бүгенге көндә Явлаштау урта мәктәбе профсоюз оешмасы составында 50 кеше исәпләнә.